| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОШУГУРОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ ШӨГЕР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
| 30 октябрь 2020 ел | № 2 |

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 15 ноябренә 13 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлар, җирлектә 18 яше тулган халыкның 30 процентынна узмаган ялгыз пенсионерлардан тыш, алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 300 сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме?:

- Иске Шөгер авыл мәдәният йорты өчен оргтехника сатып алу
- юлларны кардан чистарту, Иске Шөгер авылының С. Садри урамы 44тән 60ка кадәр вак таш салу.
- җирлек территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү (үлән чабу, чәчәкләр сатып алу)
- җирләү урыннарын карап тоту территорияләрен төзекләндерү.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Иске Шөгер авылы, Совет урамы, 1 нче йорт, Совет урамы, 3 нче йорт, М.Җәлил урамы, 33 нче йорт, Яңа Шөгер авылы, Гагарин ур., 1/а буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә

(http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.М. Шиһапова